**Катышева Ольга Дмитриевна**
**Яшел Үзән медицина училищесы укытучысы, ветеран**

Катышева Ольга Дмитриевна, 1947 елда туган, югары белемле: 1970 елда Казан дәүләт университетының биология факультетын, 2003 елда Икътисад, идарә һәм хокук институтының “Психология” факультетын, 1995 елда 2 нче Казан медицина училищесын тәмамлый. Сәламәтлек саклау системасында гомуми эш стажы – 33 ел, училищеда педагогик эш стажы – 24 ел, клиник лаборатория диагностикасы табибы стажы – 10 ел, «Шәфкать туташлары эше» бүлеге мөдире югары квалификация категориясенә һәм клиник лаборатория диагностикасы укытучысының югары квалификация категориясенә ия.

Яшел Үзән медицина училищесында эшләү дәверендә үзен укыту-тәрбия эшен оста оештыручы һәм методик яктан белемле укытучы итеп таныта. Үз эшендә чыгарылыш төркем студентларының дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә җавап бирүче югары дәрәҗәдәге һөнәри-әхлакый әзерлеге юнәлешенә таяна. Катышева О.Д. үзенең һөнәри вазыйфаларын намус белән үти, 14 ел дәвамында училище профкомы рәисе урынбасары булып эшли, хезмәттәшләренең һәм студентларның ышанычы һәм таянычы булып тора.

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау Мактау грамоталары белән бүләкләнде:

- «Шәфкать туташлары звеносы медицина кадрларын әзерләүдә озак еллар нәтиҗәле хезмәте өчен һәм 50 яшь тулу уңаеннан», 1997 ел.
- «Татарстан Республикасы урта медицина белем бирү учреждениеләре студентларының иң яхшы укыту - тикшеренү эше конкурсында җиңүе өчен» («Уку һәм һөнәри эшчәнлек этапларында шәфкать туташының шәхси сыйфатлары»), 1998 ел.

1999 елда О.Д. Катышеваның «Һөнәри белем» Казан педагогика журналында Яшел Үзән медицина училищесы студентларын һөнәри-әхлакый тәрбияләү буенча фәнни мәкаләсе басылды.

Яшел Үзән медицина училищесы директорының Рәхмәт хатларына ия:

- Татарстан Республикасы урта медицина белем бирү учреждениеләре студентларының уку - тикшеренү эшләре конкурсында җиңеп чыккан өчен, 1998 ел;
- Татарстан Республикасы урта медицина белем бирү учреждениеләре студентларының уку – тикшеренү эшләре конкурсында актив катнашкан өчен, 2002, 2004 еллар;
- Татарстан Республикасы урта махсус уку йортлары арасында үткәрелгән «Киләчәк Россия сәламәтлеге» конкурсында җиңгән өчен, 2001ел;
- Татарстан Республикасы урта медицина белем бирү учреждениеләренең «Елның иң яхшы чыгарылыш студенты» конкурсында призлы урыннар өчен 2002, 2003 еллар.

5 ел дәвамында Катышева О. Д. училищеда студентлар арасында наркотикларга каршы профилактика эше, чыгарылыш төркем студентларын эшкә урнаштыруда ярдәм итү буенча иҗтимагый бүлек белән җитәкчелек итә, гомумһөнәри дисциплиналарның методик берләшмәсе рәисе булып тора,

студентлар һәм аларның ата-аналары белән индивидуаль эшләүгә күп көч һәм игътибар бирде, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аның эшен югары бәяләде.